# Туган телем – иркә гөлем

*(Туган тел көненә багышланган "Йолдызлы сәгать" уены)*

*Сыйныф бәйрәмчә бизәлә. Мәкальләр язылган плакатлар эленә. Тактада – биремнәр. Уенда 10 укучы катнаша.*

А.б. Кадерле укучылар, укытучылар! Бүген туган тел көне. Туган телебез – татар теле – зур тарихлы, бай, җырлы, моңлы тел ул.

*Зкл. "Туган телем" җыры яңгырый.*

А.б. Татар телен камил белүегезне тикшерү өчен бүген "Йолдызлы сәгать" уены уйнарбыз. Катнашучылар, рәхим итегез!

*Чыгалар, өстәл артына басалар. Һәрберсе туган тел турында шигырьләрдән өзекләр һәм үзе турында 1-2 җөмлә әйтә.*

А.б. Мин сезгә уеныбызны күзәтеп, җыйган балларны санап утыручыларны тәкъдим итәм.

*Жюри членнары белән таныштыру*.

А.б. Туган тел! Безне хыялланырга өйрәткән әкиятләрне, тапкыр, җор телле булырга өйрәткән табышмак һәм мәкальләрне, моңлы җырларыбызны туган тел аша ишетәбез.

Уеныбызның **беренче ту**ры халык авыз иҗатына багышлана.

1) әкият;
2) җыр;
3) мәкаль;
4) санамыш;
5) тизәйткеч;
6) табышмак.

1. Теле барның юлы бар. (3)
2. Карама, карама, карамага карама,
   Карамага карасаң, ике күзең карала.(5)
3. Ак ашъяулык таптым, җир өстенә яптым. (6)
4. И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле.
   Дөньяда күп нәрсә белдем, син туган тел аркылы. (2)
5. Борын борын заманда, кәҗә командир, үрдәк үрятник булган заманда яшәгән ди әби белән бабай... (1)
6. Ипи тоз,
   Матур кыз.
   Гөрлисең килмәсә,
   Чыгып сыз! (4)
7. Тел күрке – сүз. (3)
8. Әке,пәке, кыек сәке.
   Эремчек,
   Син кал, бу чык.(4)
9. Җәен соры, кышын ак,

   Аңа шулай яхшырак. (6)

10. Өйгә кергән чыпычык,
Очып йөри чып-чып
Чыпчык, чыпчык, чык, чыпчык
Очып чык, чыпчык, кошчык. (5)
Йолдызлар санала, иң аз очко җыйган 2 укучы чыга.

А.б. Дәү әни, дәү әти – татарча матур әкиятләр, бәетләр,шигырьләр сөйли белә торган, гореф-гадәтләрне саклаучы иң якын кешеләребез.

“Дәү әнидә кунакта” җыр 3 кл.

А.б. **2нче турда** әби-бабайлар сөйләгән әкиятләрне, мәкаль-әйтемнәрне яхшы белүегез кирәк булыр.

4 әкияткә иллюстрация эленә.

1) Су анасы;
2) Шүрәле;
3) Нечкәбил;
4) Сертотмас үрдәк.

- Бу өзек кайсы әкияттән? (авторы, әкият исеме)

Магнитофон тасмасында:

-“Су анасы” Г.Тукай (1)

- “Сертотмас үрдәк” А.Алиш. (4)

- Мәкальнең дәвамын тап!

1) Иң татлы тел – туган тел, (анам сөйләп торган тел).
2) Туган телем – иркә гөлем (киңдер сиңа күңел түрем).
3) Туган телен кадерләгән халык (кадерле булыр).
4) Теле татлының (дусы күп).

Йолдызлар санала, 2 укучы уеннан чыга.

А.б. Безнең республикада туган теле төрле булган күп милләт кешеләре яши. Алар барысы да дус, тату.

*Җыр “Мин яратам, сине Татарстан”*

А.б. **3нче тур** Туган илебез – Татарстан бик матур һәм бай ил. Урман-күлләрендә төрледән-төрле кош-корт һәм җәнлекләр яши, болыннарда, бакчаларда төрле үләннәр, җиләк-җимеш, яшелчәләр үсә.

Тактада, минемчә, барысы да кыргый хайван рәсемнәре. Дөресме? Хаталы рәсем номерын күтәр!

1) бүре;
2) аю;
3) эт;
4) төлке;
5) тиен;
6) куян

- Минемчә, монда барысы да яшелчәләр. Дөресме? Хаталы номерны күтәр.

| | |
|---|---|
| 1) кәбестә; | 1) җиләк |
| 2) помидор; | 2) крыжовник; |

| | |
|---|---|
| 3) кыяр; | 3) йөзем |
| 4) кишер; | 4) кыяр; |
| 5) алма; | 5) карлыган |
| 6) бәрәңге; | 6) чикләвек; |

*Йолдызлар санау, 4 җиңүче билгеләнмәсә, табышмак чишү ярышы:*

Өстенә кигән йөз күлмәк. (1)
Утыра бер ак чүлмәк,

Кечкенә генә йорт,
Эче тулы корт. ( 3)

Яфракларын чәйгә салалар,
Җимеше кызыл да, кара да,
Вак-вак тәмле бөртекләр
Нәрсә була, балалар? (5)

Йомры-йомры таш кына,
Эче тулы төш кенә.
Вата алсан таш тышын
Ашарсың тәмле төшен. (6)

*“Хәерби авылы көе” 4кл.*

А.б. Бу **4 нче** турда барлык карап утыручылар да катнаша ала. Тактада – хәрефләр. Шул хәрефләр белән иң озын сүз төзегән укучы җиңә.

Ш М Е Җ Ө Л Г И *

*Карап утыручылардан сорау*: Кем 6 сүздән торган сүз төзеде?

А.б. Тиздән зур бәйрәм – халыкара хатын кызлар бәйрәме җитә. Хәзер әни турында җыр тыңлап китик.

*Җыр: “ Әниемә бүләгем” 3кл.*

А.б. Ниһаять, иң соңгы тур – **финал**га килеп җиттек.

Ике укучы кара-каршы утыра, уртага бер сүз куела – **башваткыч.**

Иң күп сүз төзи алган укучы җиңә. (*Кара-каршы әйтешәләр*)

*Йомгаклау, нәтиҗә чыгару, җиңүчене бүләкләү.*

А.б. Бергәләп җырлыйк “Туган тел” җырын,

Онытканнарның бәгырен телеп,
Мин бит татар баласы, диеп,
Кешеләр һәрчак торсыннар белеп.

*Җыр “Туган тел”*

А.б. Туган телгә багышланган уен – кичәбез тәмам. Катнашучы укучыларга, карап утыручыларга һәм жюрида утыручыларга зур рәхмәт.